# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

**18.03.2024 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Балан-Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында», 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Балан-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Балан-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында » карарларына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Балан-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 09.11.2023 № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Балан-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 09.11.2023 № 2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Ленин урамы буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Балан-Бүләк авылында урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);

3) Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( материаллар сатып алу, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);

4) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Балан-Бүләк торак пунктында үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү).».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге Башлыгы А.М.Мөхәмәтшин